ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 июль 2018 ел № 4055

2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законга, шәһәр Уставының 41 маддәсенә, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карарына, Башкарма комитетның «Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезнамәне раслау турында» 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карарына туры китереп

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 19 июлендәге
4055 нче карарына
кушымта

2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең
«1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сарае» муниципаль автономияле
өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| 1. | Укучылар өчен интеллектуаль уен үткәрү | сум/кеше | 54,85 |
| 2. | Укучылар өчен интеллектуаль уен үткәрү (урынга барып) | сум/кеше | 75,39 |
| 3. | Укучылар өчен спорт уены үткәрү | сум/кеше | 54,56 |
| 4. | Укучылар өчен спорт уены үткәрү (урынга барып) | сум/кеше | 75,69 |
| 5. | «Яр буе» паркы территориясендә спорт-сәламәтләндерү чарасы үткәрү | сум/кеше | 109,46 |
| 6. | Укучылар төркеме өчен театр чарасы үткәрү | сум/кеше | 539,58 |
| 7. | Массакүләм театр тамашасы | сум/кеше | 446,29 |
| 8. | Кинотеатрда киносеанс | сум/кеше | 54,36 |
| 9. | Этнография музеена экскурсия | сум/кеше | 53,85 |
| 10. | Укучылар төркеме өчен интерактив викторина | сум/кеше | 51,47 |
| 11. | Укучылар төркеме өчен күңел ачу-танып белү программасы (мастер-класс) | сум/кеше | 53,92 |
| 12. | Театр залында чара оештыру һәм үткәрү | сум/кеше | 2532,54 |
| 13. | Концерт залында чара оештыру һәм үткәрү | сум/кеше | 3568,3 |
| 14. | Батутны прокатка бирү | сум/5 минут | 50,35 |
| 15. | Өстәл теннисын прокатка бирү (1 өстәл) | сум/сәгать | 159,67 |
| 16. | Костюмнарны прокатка бирү | сум/тәүлек | 548,96 |
| 17. | Психолог белән индивидуаль дәрес (1 дәрес) | сум/дәрес | 502,66 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ